ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.01.2019 Алексеевск ш.т.б. № 44

**«2019-2021 елларга Алексеевск муниципаль районы яшьләренә патриотик тәрбия бирү» программасын раслау турында**

Иҗтимагый һәм икътисади тотрыклылыкны тәэмин итүче патриотик тәрбия системасын үстерү һәм модернизацияләү максатларында, Алексеевск муниципаль районы балаларында һәм яшьләрендә гражданнар тәңгәллеген формалаштыру, югары патриотик аң, Ватанга тугрылык булдыру, Конституция бурычларын, толерантлыкны, милләтара һәм конфессияләр арасындагы мөнәсәбәтләр мәдәниятен үтәүгә әзерлек максатында, Алексеевск муниципаль районы Уставына таянып

**карар бирәм:**

1. "2019-2021 елларга Алексеевск муниципаль районы яшьләренә патриотик тәрбия бирү» муниципаль программасын расларга (Кушымта).

2. Шәһәр һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләренә, яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә (Сөләйманов Р. Б.), Башкарма комитетның мәдәният бүлегенә (Соловьев А. Г.), «Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ (Гыйләҗев Д. А.) «2019-2021 елларга Алексеевск муниципаль районы яшьләренә патриотик тәрбия бирү» муниципаль программасының үтәлешен тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

3. Финанс-бюджет палатасына (Леденцов О. Н.) «мәгариф», «мәдәният», «яшьләр сәясәте» һәм «спорт» тармаклары буенча каралган бюджет акчаларыннан Программа чараларын гамәлгә ашыру өчен акча бүлеп бирүне күздә тотарга.

4. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http//alekseevskiy.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча бастырып чыгарырга:

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Н.П. Чуринга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К. Кадыров**

Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
31.01.2019 № 44
карарына кушымта

**«2019-2021 елларга Алексеевск муниципаль районы яшьләренә патриотик тәрбия бирү» муниципаль программасы**

## Программаның паспорты

| | |
|---|---|
| **Программаның исеме** | «2019-2021 елларга Алексеевск муниципаль районы яшьләренә патриотик тәрбия бирү» муниципаль программасы (алга таба – Программа) |
| **Программа эшләү өчен нигез** | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2011-2015 елларга Россия Федерациясе гражданнарына патриотик тәрбия бирү» дәүләт программасы турында» 2010 елның 5 октябрендәге 795 номерлы карары |
| **Программаны төзүче** | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге. |
| **Программаның максатлары** | Патриотик тәрбия системасын үстерү һәм модернизацияләү, Алексеевск муниципаль районы балаларында һәм яшьләрендә гражданнар тәңгәллеген формалаштыру, югары патриотик аң, Ватанга тугрылык булдыру, Конституция бурычларын, толерантлыкны, милләтара һәм конфессияләр арасындагы мөнәсәбәтләр мәдәниятен үтәүгә әзерлек. |
| **Программаның бурычлары** | • Яшьләрне патриотик тәрбияләү буенча эш юнәлешләрен һәм формаларын камилләштерү;<br>• Яшьләрне хәрби-һөнәри ориентлаштыру, аларны хәрби хезмәткә әзерләү;<br>• Җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм патриотик юнәлештәге |

| | |
|---|---|
| | оешмалар, мәгариф, социаль яклау системасы учреждениеләре, массакүләм мәгълүмат чаралары арасында ведомствоара хезмәттәшлекне үстерү;<br>• Патриотик тәрбия бирү буенча белгечләрне әзерләү, яңадан әзерләү һәм аларның квалификацияләрен үстерүне оештыру;<br>• Патриотик тәрбия бирү эшен фәнни һәм мәгълүмати тәэмин итү. |
| **Программаны гамәлгә ашыру сроклары** | 2019-2021 еллар |
| **Бүлекләрнең исемлеге** | Программа чаралары түбәндәге юнәлешләр буенча системалаштырыла:<br>1. Патриотик тәрбия бирү процессын камилләштерү:<br>- хәзерге этапта патриотик тәрбия бирү буенча эшнең өстенлекле юнәлешләрен билгеләү;<br>- патриотик тәрбия бирү эшенең эчтәлеген баету;<br>- патриотик тәрбия бирүнең инновацион формаларын һәм методларын үстерү;<br>- Ватанны саклаганда һәлак булган сугышчылар истәлеген мәңгеләштерү;<br>- Ватанны саклау бурычларын үтәүгә җәмгыятькә һәм дәүләткә лаеклы һәм фидакяр хезмәт итүгә әзерлек тәрбияләү;<br>- патриотик тәрбия бирү процессы белән идарә итү системасын камилләштерү;<br>- патриотик тәрбия бирү өлкәсендә белгечләр әзерләү системасын камилләштерү.<br>2. Гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү:<br>- хәрби хезмәтнең абруен күтәрү;<br>- яшьләрне физик һәм психологик яктан әзерләү;<br>- спортның хәрби-гамәли, спорт-техник төрләрен популярлаштыру;<br>- гражданнарны хәрби хезмәт нигезләренә өйрәтү.<br>3. Алексеевск муниципаль районында яшәүчеләргә патриотик тәрбия бирү мәнфәгатьләрендә иҗтимагый оешмаларның эшчәнлеген координацияләү:<br>- патриотик тәрбия эшендә иҗтимагый оешмаларның катнашуы өчен шартлар тудыру;<br>- мәдәният учреждениеләренең, иҗтимагый оешмаларның, иҗат интеллигенциясе вәкилләренең катнашуын активлаштыру; |

| | |
|---|---|
| | - хәрби хезмәткәрләрне Алексеевск муниципаль районында яшәүчеләрнең мәдәният байлыкларына җәлеп итүгә юнәлдерелгән хәрби-шефлык эше;<br>- Алексеевск муниципаль районы халкының патриотик аңын формалаштыруга юнәлдерелгән иҗтимагый-тәрбия йогынтысының актив формаларын үстерү.<br>4. Яшь гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү буенча чаралар.<br>5. Патриотик тәрбия бирү өлкәсендә мәгълүмати, фәнни-теоретик һәм методик тәэмин ителеш. |
| **Финанслау күләме һәм чыганаклары** | - Программаны финанслау Алексеевск муниципаль районы бюджеты, бюджеттан тыш чыганаклар, республика бюджеты акчалары хисабына билгеләнгән күләмдә һәм билгеләнгән тәртиптә башкарылачак.<br>- Программаны финанслау күләме җирле бюджет акчалары хисабына. |
| **Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре** | Районда патриотик тәрбия инфраструктурасын модернизацияләү:<br>- патриотик берләшмәләрдә, клубларда торучы балалар һәм яшьләр санын 15% ка арттыру;<br>- эзтабарлык хәрәкәтендә катнашучылар санын 10% ка арттыру;<br>- яшьләрнең рухи-әхлакый мәдәнияте дәрәҗәсен күтәрү;<br>- яшьләрне армия хезмәтенә әзерләү эшен камилләштерү;<br>- балаларны һәм яшьләрне патриотик юнәлештәге чараларга җәлеп итү эшен 30% ка арттыру;<br>- патриотик тәрбия бирү өлкәсендә белгечләр әзерләү эшен яхшырту һәм патриотик тәрбия бирүнең сыйфатын күтәрү. |
| **Программаны тормышка ашыручылар** | - Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге;<br>- «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге » МКУ;<br>- Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге;<br>- ТР Алексеевск РОСТО (ДОСААФ) (килешү буенча);<br>- Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының Алексеевск районындагы бүлеге |

| | |
|---|---|
| | (килешү буенча);<br>- Алексеевск муниципаль районы «ИМПУЛЬС» клубы » өстәмә белем бирүче МБУ;<br>- Алексеевск муниципаль районы «Яшьармияче» клубы » өстәмә белем бирүче МБУ;<br>- ДАҺББУ «Алексеевск аграр көллияте»;<br>- Алексеевск муниципаль районының " ФОРПОСТ» үзәге. |

**Программаның чишелешенә юнәлдерелгән проблеманың характеристикасы**

Әлеге программа 2003 елның 21 маенагы Хөкүмәт комиссиясе утырышында хәрби хезмәткәрләрнең, хәрби хезмәттән азат ителгән гражданнарның һәм аларның гаилә әгъзаларының социаль мәсьәләләре буенча хупланган Россия Федерациясе гражданнарын патриотик тәрбияләү концепциясе нигезендә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 05 октябрендәге 795 ноерлы карары белән расланган «2016-2020 елларга Россия Федерациясе гражданнарын патриотик тәрбияләү» дәүләт программасы нигезендә эшләнгән.

Программа төп максат булып патриотик тәрбия системасын булдыру билгеләнгән «2014-2018 елларга Алексеевск муниципаль районы яшьләренә патриотик тәрбия бирү» муниципаль программасының логик дәвамы һәм үсеше булып тора.

Үсеп килүче буынны патриотик яктан тәрбияләү һәм гражданлык үсешен булдыру проблемасы бүгенге көндә дәүләт һәм җәмгыятьнең актуаль бурычларыннан берсе булып тора. Россия Федерациясе мәгарифенең милли доктринасында мәгариф өлкәсендәге дәүләт сәясәте генә түгел, ә актив тормыш позициясе булган, хезмәт сөючән һәм югары әхлаклы, ватанпәрвәр, шәхес хокукларын һәм ирекләрен хөрмәт итүче, милли һәм дини түземлек күрсәтүче башка халыкларның традицияләрен һәм мәдәниятен хөрмәт итүче кеше тәрбияләүгә дәүләт социаль заказы да билгеләнгән. Дөньядагы хәрби-сәяси вәзгыятьнең үзгәрүе Ватаныбызның икътисади көчен ныгытуны, аның оборона сәләтен арттыруны, үсеп килүче буынны патриотик тәрбияләү системасының җайга салынган эшен, аларны Ватанны саклауга әзерләүне таләп итә.

Җәмгыятькә, аның хакына эшләргә һәм укырга әзер булган, сәламәт, кыю, батыр, инициативалы, тәртипле, белемле

кешеләр кирәк. Шуңа күрә яшь буынны тәрбияләүдә патриотлык, Ватанга мәхәббәт хисләре тәрбияләүгә аерым урын бирелә.

Әлеге Программа муниципаль структураларның һәм иҗтимагый оешмаларның патриотик тәрбия мәсьәләләренең киң спектрын чишүдә уртак эшчәнлеген киңәйтүне күздә тота һәм бу процесска алга таба динамика бирергә тиеш.

## II. Программаны тормышка ашыруның төп юнәлешләре

1. Патриотик тәрбия процессын камилләштерү.

Патриотик тәрбия процессын камилләштерү системасы түбәндәгеләрне күздә тота:

- хәзерге этапта патриотик тәрбия бирү буенча эшнең өстенлекле юнәлешләрен билгеләү;
- патриотик тәрбия бирүнең эчтәлеген баету;
- патриотик тәрбия бирүнең инновацион формаларын һәм методларын үстерү;
- Ватанны саклаганда һәлак булган сугышчылар истәлеген мәңгеләштерү;
- Ватанны саклау бурычларын үтәүгә җәмгыятькә һәм дәүләткә лаеклы һәм фидакяр хезмәт итүгә әзерлек тәрбияләү;
- Алексеевск муниципаль районы авыл җирлекләренең патриотик тәрбия өлкәсендә үзара хезмәттәшлеген һәм эшен координацияләүне тәэмин итү;
- патриотик тәрбия бирү процессы белән идарә итү системасын камилләштерү;
- патриотик тәрбия бирү өлкәсендә белгечләр әзерләү системасын камилләштерү.

2. Гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү.

Гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү буенча чаралар системасы тарафыннан берничә чара күздә тотыла:

- хәрби хезмәтнең абруен күтәрү;
- яшьләрне физик һәм психологик яктан әзерләү;
- спортның хәрби-гамәли, спорт-техник төрләрен популярлаштыру;
- гражданнарны хәрби хезмәт нигезләренә өйрәтү.

3. Алексеевск муниципаль районында яшәүчеләрне патриотик тәрбияләү мәнфәгатьләрендә иҗтимагый оешмалар эшчәнлеген координацияләү.

Алексеевск муниципаль районында яшәүчеләрне патриотик тәрбияләү мәнфәгатьләрендә иҗтимагый оешмалар

(берләшмәләр) эшчәнлеген координацияләү чаралары системасында түбәндәгеләр карала:

- патриотик тәрбия эшендә иҗтимагый оешмаларның катнашуы өчен шартлар тудыру;
- мәдәният учреждениеләренең, иҗтимагый оешмаларның, иҗади интеллигенция вәкилләренең хәрби хезмәткәрләрне Алексеевск муниципаль районында яшәүчеләрнең мәдәният байлыкларына җәлеп итүгә юнәлдерелгән хәрби-шефлык эшендә катнашуын активлаштыру,
- Алексеевск муниципаль районы халкының патриотик аңын формалаштыруга юнәлдерелгән иҗтимагый-тәрбия йогынтысының актив формаларын үстерү.

## III. Программаның төп максатлары һәм бурычлары

Программаның төп максаты – районда иҗтимагый һәм икътисади тотрыклылыкны тәэмин итүче патриотик тәрбия системасын үстерү һәм модернизацияләү, балаларда һәм яшьләрдә гражданлык тәңгәллеген, югары патриотик аң, Ватанга тугрылык, конституциячел бурычларны үтәргә әзерлекне формалаштыру тора.

Әлеге максатларга ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

- патриотик тәрбия инфраструктурасын камилләштерү;
- җирле үзидарә органнары, патриотик юнәлештәге иҗтимагый оешмалар, мәгариф учреждениеләре, массакүләм мәгълүмат чаралары белән ведомствоара хезмәттәшлекне үстерү;
- балалар һәм яшьләрдә гражданлык тәңгәллеген, патриотик, мораль-әхлакый һәм толерант дөньяви караш формалаштыру, Ватанны саклау буенча конституциячел бурычларны үтәүгә әзерлек буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру;
- яшьләрне патриотик тәрбияләү буенча эш юнәлешләрен һәм формаларын камилләштерү;
- белем бирү учреждениеләрендә, иҗтимагый берләшмәләрдә патриотик тәрбия бирүнең сыйфатын күтәрү;
- белгечләрне әзерләүне, яңадан әзерләүне һәм квалификацияләрен үстерүне оештыру.

## IV. Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре

Программаны тормышка ашыруның соңгы нәтиҗәсе буларак илдә патриотизм үсешенең уңай динамикасы, гражданнарның, бигрәк тә яшьләрнең социаль һәм хезмәт активлыгын арттыру, аларның җәмгыять һәм дәүләт

эшчәнлегенең төп өлкәләрен үстерүгә керткән өлеше, гражданнарның аерым төркемнәренең экстремистик күренешләрен һәм башка тискәре күренешләрне җиңеп чыгу, рухиятне торгызу, социаль-икътисади һәм сәяси тотрыклылык һәм милли иминлекне ныгыту күздә тотыла.

## «2019-2021 ЕЛЛАРГА АЛЕКСЕЕВСК РАЙОНЫ ЯШЬЛӘРЕНӘ ПАТРИОТИК ТӘРБИЯ БИРҮ» РАЙОН ПРОГРАММАСЫН ТОРМЫШКА АШЫРУ БУЕНЧА ЧАРАЛАР ПЛАНЫ

| № | Планда каралган чаралар | Җаваплы башкаручылар | Үтәлеш вакыты (еллар) | Елларга бүленгән чыгымнар суммасы (мең сумнар) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 |
| 1 | Укучылар һәм аларның ата-аналары өчен патриотик һәм рухи-әхлакый дөньяга караш формалаштыру, гражданлык дәрәҗәсен күтәрү максатыннан чаралар үткәрү (айлыклар, ункөнлекләр, хәрби-спорт уеннары, фестивальләр) | МәгБ, МәдБ, ЯЭСТБ, МББУ | 2019-2021 | 16,0 | 16,0 | 16,0 |
| 2 | Хәрби-патриотик клублар һәм эзләнү отрядлары эшчәнлеген оештыру | МәгБ, МББУ | 2019-2021 | 15,0 | 15,0 | 15,0 |
| 3 | Хәрби-патриотик клублар һәм эзләнү отрядлары вәкилләренең /укучыларның, педагогларнын/ фестивальләрдә, семинарларда, эзләнү экспедицияләрендә катнашуын тәэмин итү | МәгБ, ЯЭСТБ | ел саен | 115,0 | 115,0 | 120,0 |
| 4 | Педагогларның, укучыларның муниципаль, республика, бөтенроссия дәрәҗәсендәге бәйгеләрдә, фәнни-гамәли конференцияләрдә, семинарларда катнашуын тәэмин итү | МәгБ, ЯЭСТБ | 2019-2021 | 10,0 | 15,0 | 15,0 |
| 5 | Волонтерлар хәрәкәтен үстерү, ветераннар, тыл хезмәтчәннәре, «сугыш чоры балалары» шефлыгы, аларга хуҗалык буенча кулдан килгәнчә ярдәм итү, обелисклар янында чисталык һәм тәртип саклау | МәгБ, СЯБ | 2019-2021 | - | - | - |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 6 | Мәктәп музейлары эшчәнлеген активлаштыру, аларның фондларын тулыландыруга һәм экспозицияләрен яңартуга ярдәм итү | МәгБ, МәдБ | 2019-2021 | 10,0 | 15,0 | 15,0 |
| 7 | Җәен һәм каникуллар вакытында төрле типтагы лагерьларда (шул исәптән профильле сменаларда: спорт, хәрби-патриотик лагерьларда) укучыларның ялын һәм мәшгульлеген оештыру | МәгБ, СЯБ, ЯЭСТБ | 2019-2021 | 125,0 | 130,0 | 145,0 |
| 8 | Музейларга, тематик күргәзмәләргә йөрүне оештыру, фильмнар һәм спектакльләр карау | МәгБ, ЯЭСТБ, МәдБ, «Кама» кинотеатры | 2019-2021 аерым график буенча | - | - | - |
| 9 | Район хәрби-спорт уеннарын үткәрү: «Аҗаган», «Яшь армиячеләр алга» | ЯЭСТБ, МәгБ | 2019-2021 | 45,0 | 45,0 | 45,0 |
| 10 | Укучылар өчен спорт-сәламәтләндерү уеннарының район этабын үткәрү һәм республика турында катнашу | МәгБ, ЯЭСТБ | 2019-2021 | 25,0 | 30,0 | 30,0 |
| 11 | Бөек Ватан сугышында Җиңү көненә багышланган бәйрәм чараларын оештыру (аерым план буенча) | СЯБ, ЯЭСТБ, МәдБ, МәгБ, РОСТО (ДОСААФ), АЖ, ВОС | 2019-2021 | 95,0 | 95,0 | 120,0 |
| 12 | Район фестивальләре һәм акцияләр үткәрү:<br>- хәрби-патриотик җырларның район фестивален оештыру<br>- «Мин – Россия гражданины» паспорт тапшыру буенча яшьләр өчен патриотик акция оештыру һәм үткәрү | МәдБ, МәгБ, ЯЭСТБ.<br>ТР буенча ФМХИ | 2019-2021 | 55,0 | 55,0 | 55,0 |
| 13 | Мемориаль такталарның, һәйкәлләрнең, Ватанны саклаучылар мемориалларының торышын һәм аларны тәртипкә китерүне күзәтү. | РБК, АЖ | 2019-2021 | 120,0 | 120,0 | 120,0 |
| 14 | Ветераннар Советы белән берлектә яшьләр эстафеталары, Россиянең Хәрби дан көннәренә багышланган акцияләр оештыру | ВОС, ЯЭСТБ, МәгБ, МәдБ | 2019-2021 | - | - | - |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 15 | Җәмәгать тәртибен саклау буенча мәктәп оешмалары отрядларын үстерү чаралары | ЯЭСТБ, МәгБ, Алексеевск районының ЭЭБ | 2019-2021 | 10,0 | 15,0 | 15,0 |
| 16 | Җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр оешмаларының Республика спартакиадасында катнашу | ЯЭСТБ, МәгБ | 2019-2021 | 15,0 | 15,0 | 15,0 |
| 17 | Совет гаскәрләрен Әфганстаннан чыгаруга багышланган чаралар үткәрү | ЯЭСТБ, СЯБ, ВОС | 2019-2021 | 60,0 | 65,0 | 65,0 |
| 18 | Егетләрне хәрби-учет белгечлекләре буенча әзерләү | РОСТО-ДОСААФ, МәгБ, ХКБ | 2019-2021 | - | - | - |
| 19 | Районкүләм хәрби хезмәткә чакырылучылар көнен үткәрү (елга ике тапкыр) | ЯЭСТБ, ХКБ, МәдБ | 2019-2021 | 65,0 | 65,0 | 70,0 |
| 20 | Патриотик тәрбия буенча укыту-методик әсбаплар сатып алу | МәгБ | 2019-2021 | 10,0 | 10,0 | 10,0 |
| 21 | Бөек Ватан сугышында, локаль сугышларда һәм конфликтларда һәлак булган һәм вафат булган сугыш ветераннарына һәм һәлак булучыларның тол хатыннарына ярдәм күрсәтү буенча Бөтенроссия тимурчылар хәрәкәтендә катнашу. | ЯЭСТБ, МәгБ | 2019-2021 | - | - | - |
| 22 | Ветераннар иҗтимагый оешмаларына ярдәм итү. | ВОС, РБК СЯБ, МҮ | 2019-2021 | - | - | - |
| 23 | Патриотик юнәлештәге реклама такталары, стендлар һәм плакатлар урнаштыру. | РБК | 2019-2021 | 20,0 | 20,0 | 20,0 |
| 24 | Хәрби-тарихи нәфис һәм документаль фильмнар күрсәтү | МәдБ | 2019-2021 | - | - | - |
| 25 | Белем бирү учреждениеләрендә иң яхшы кадетлар сыйныфы (төркеме) бәйгесе. | ЯЭСТБ, МәгБ | 2019-2021 | 25,0 | 35,0 | 45,0 |
| 26 | Патриотик һәм спорт юнәлешендәге профильле палаткалы лагерьлар үткәрү. | ЯЭСТБ | 2019-2021 | 25,0 | 25,0 | 25,0 |
| 27 | Уку йортларында хәрби дан музейларының эшен | ЯЭСТБ, МәгБ | 2019-2021 | - | - | - |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | анализлау. Һәр уку йортында музей, зал, сугышчан дан почмагы булдыру (яңарту) мөмкинлеген каракрга. | | | | | |
| 28 | Сталинград сугышында Җиңүнең 75 еллыгына һәм Ленинград блокадасы өзелүгә багышланган укучыларның иҗади эшләренә күргәзмә-бәйге. | МәгБ | 2019-2021 | 14,0 | 14,0 | 14,0 |
| 29 | «Легендалардагы кешеләр» иҗади проектлар бәйгесе. «Безнең як һәм сугыш елларында аның кешеләре» темасына мәктәпләрдәге туган якны өйрәнү проект-тикшерену эшләренең күргәзмәсе. | МәгБ | 2019-2021 | 20,0 | 20,0 | 20,0 |
| 30 | Россия, Татарстан, Алексеевск районының патриотик, тарихи һәм заманча символикасын чагылдыручы күрсәтмә әсбаплар, плакатлар, сувенир продукцияләре ясау һәм чыгару. | ЯЭСТБ | 2019-2021 | 25,0 | 25,0 | 25,0 |
| 31 | Хәрби-гамәли һәм техник спорт төрләре буенча «Ватанның тугрылыклы уллары» ярышларында катнашу. | ЯЭСТБ, МәгБ | 2019-2021 | 10,0 | 15,0 | 15,0 |
| 32 | Россиянең Хәрби дан көненә һәм истәлекле даталарына багышланган батырлык дәресләре, сыйныф сәгатьләре, әдәби кичәләр, класстан тыш чаралар үткәрү. | МәгБ | 2019-2021 | - | - | - |
| 33 | Предприятиеләрне, оешмаларны, яшьләр берләшмәләрен хезмәт коллективларын патриотик тәрбия эшендә катнашуга җәлеп итү. | РБК | 2019-2021 | - | - | - |
| 34 | Советлар Союзы Геройлары исемнәрен йөртә торган урамнарны төзекләндерү. | ААК, яшьләр оешмалары, волонтерлар | 2019-2021 | - | - | - |
| 35 | Уку йортларында сугыш һәм хезмәт ветераннарының балалар һәм яшьләр белән очрашуларын оештыру. | МәгБ, ЯЭСТБ, МәдБ | 2019-2021 | - | - | - |
| 36 | Бөек Ватан сугышы һәм хезмәт ветераннары исемлеген даими яңарту. | СЯБ | 2019-2021 | - | - | - |
| 37 | Яшьләрне хәрби хезмәткә әзерләү мәсьәләләре буенча дәүләт органнары һәм башка оешма җитәкчеләре белән | ХКБ, РБК | 2019-2021 | - | - | - |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | укыту-методик киңәшмәләр һәм конференцияләр үткәрү. | | | | | |
| 38 | Уку йортларының матди-техник, гамәли һәм спорт базасын ныгыту буенча эш. | РБК | 2019-2021 | 23,0 | 23,0 | 23,0 |
| 39 | Хәрби хезмәткә чакыру чорында яшьләр белән төрле чаралар циклын үткәрү (ветераннар белән очрашулар, ачык ишекләр көне һ. б.) | ЯЭСТБ, ХКБ, МәгБ, РОСТО (ДОСААФ) | 2019-2021 | - | - | - |
| 40 | Тантаналы рәвештә хәрби ант кабул итү, хәрби дан музейларында кадетның ант бирүләрен хәрби хезмәткә кадәрге яшьтә булган яшьләрне, ата-аналарны, ветераннарны чакырып, һәйкәлләр һәм обелисклар янында үткәрү практикасын үстерү. | ХКБ, МәгБ | 2019-2021 | - | - | - |
| 41 | Армиягә кадәрге яшьләр арасында«Патриот» комплекслы ярышларын үткәрү. | ЯЭСТБ, РОСТО (ДОСААФ) | 2019-2021 | 10,0 | 10,0 | 10,0 |
| 42 | Рус армиясенең тарихи җиңүләренә, Бөек Ватан сугышы елларында совет гаскәрләренең җиңүләренә, Җиңү бәйрәменә багышланган ату буенча спорт ярышлары. | ЯЭСТБ, РОСТО (ДОСААФ) | 2019-2021 | 10,0 | 10,0 | 10,0 |
| 43 | Севастопольдәге Россия Кара диңгез флоты коткару корабларының 37 нче бригадасы белән шефлык элемтәләрен үстерү. | РБК, ХКБ | 2019-2021 | 340,0 | 340,0 | 340,0 |
| 44 | Алексеевск районыннан булган хәрби хезмәткәрләрнең хәрби хезмәт үтә торган частьләре белән хат алышу. Посылкалар, открыткалар җыю һәм җибәрү, Алексеевск хәрбиләренә мораль ярдәм күрсәтү, хәрби частьләрдән аларга бәяләмәләр соратып алу. | ЯЭСТБ, РОСТО (ДОСААФ), ХКБ, МәгБ | 2019-2021 | - | - | - |
| 45 | Хәрби хезмәткәрләрнең ата-аналары белән очрашу. | РБК, ХКБ | 2019-2021 | - | - | - |
| 46 | Белем бирү учреждениеләрендә балаларны һәм яшьләрне армия хезмәтенә әзерләү буенча күрсәтмә бәйгеләр үткәрү. | МәгБ, ЯЭСТБ | 2019-2021 | - | - | - |
| 47 | Хәрби хезмәткә чакырылучылар өчен «Яшьләрне хәрби | ХКБ | 2019-2021 | - | - | - |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | хезмәткә әзерләү» бәйгесен оештыру. | | | | | |
| 48 | Белем бирү учреждениеләренә кертү өчен балаларны һәм яшьләрне хәрби-патриотик тәрбияләү эшен яхшырту буенча фәнни-теоретик һәм гамәли тәҗрибәне исәпкә алып методик кулланмалар эшләү. | МәгБ, ЯЭСТБ, ХКБ | 2019-2021 | - | - | - |
| 49 | Белем бирү учреждениеләрендә патриотик тәрбия бирү эшен оештыручыларның квалификация күтәрү курслары эшендә катнашуларын оештыру. | МәгБ | 2019-2021 | 20,0 | 20,0 | 20,0 |
| 50 | Патриотик тәрбия темасын ММЧда иң яхшы яктыртуга «Россия патриоты» Бөтенроссия бәйгесендә катнашу. | «Заря», «Таң» газетасы, ЯЭСТБ | 2019-2021 | - | - | - |
| 51 | Алексеевск муниципаль районы сайтында «Балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү» бүлеген төзү һәм даими яңарту . | ЯЭСТБ | 2019-2021 | - | - | - |
| 52 | Китапханәләрне патриотик һәм туган якны өйрәнү юнәлешендәге әдәбият белән тулыландыру. | МәдБ, МәгБ | 2019-2021 | 15,0 | 20,0 | 20,0 |
| 53 | Патриотик, гражданлык һәм толерант тәрбия өлкәсендә волонтерлар өчен семинар-тренинг үткәрү. | ЯЭСТБ, ААК яшьләр оешмалары | 2019-2021 | - | - | - |
| 54 | Хәрби-патриотик һәм гражданлык тәрбиясе мәсьәләләре буенча район конференциясен үткәрү. | МәгБ | 2019-2021 | - | - | - |
| 55 | Патриотик тәрбия өлкәсендә республика семинар-киңәшмәләрендә, конференцияләрдә, белем арттыру буенча курсларында катнашу. | МәгБ, ЯЭСТБ | 2019-2021 | 10,0 | 10,0 | 10,0 |
| 56 | Патриотик тәрбия бирү мәсьәләләре буенча социологик тикшеренүләр үткәрү. | ЯЭСТБ, МәгБ | 2019-2021 | - | - | - |
| 57 | Яшьләр берләшмәләре, патриотик клублар һәм берләшмә җитәкчеләре белән «Россиядә Гражданлык җәмгыятен формалаштыруда яшьләрнең катнашуы» темасына «түгәрәк өстәл» утырышлары үткәрү. | ЯЭСТБ, ААК, яшьләр оешмаларының лидерлары | 2019-2021 | - | - | - |
| 58 | Спорт һәм патриотик юнәлештәге профильле палаткалы | ЯЭСТБ, МәгБ | 2019-2021 | - | - | - |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | лагерьларда эшләү өчен педагог-тәрбиячеләрне әзерләү буенча семинарлар үткәрү. | | | | | |
| 59 | «Заря» (Тан») газетасы битләрендә хәрби-патриотик клублар, түгәрәкләр эшчәнлеген яктыртучы сәхифәләр булдыру. | «Заря» (Таң») газетасы | 2019-2021 | - | - | - |
| | | **Барлыгы:** | | **1353.0** | **1408.0** | **1468.0** |

**Шартлы билгеләмәләр:**

**Мәгариф Бүлеге (МәгБ), Мәдәният Бүлеге (МәдБ), Яшьләр Эшләре, Спорт һәм Туризм Бүлеге (ЯЭСТБ), Мәктәпкәчә Белем Бирү Учреждениеләре (МББУ), Мәшгульлек Үзәге (МҮ), Авыл Хуҗалыгы һәм Азык-төлек Идарәсе (АХАИ), Инфраструктура Үсеше Бүлеге (ИҮБ), Ветераннар Оешмалары Советы (ВОС), Авыл Җирлекләре (АҖ), Хәрби Комиссариат Бүлеге (ХКБ), Район башкарма комитеты (РБК), Алексеевск Аграр Көллияте (ААК), Социаль Яклау Бүлеге (СЯБ), Мәшгульлек үзәге (МҮ), Федераль Миграция Хезмәте Идарәсе (ФМХИ), Эчке Эшләр Бүлеге (ЭЭБ)**

**Башкарма комитет эшләре
белән идарә итүче** **Г.А.Юсупова**